# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О градостроительной деятельности в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 марта 2023 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 25 декабря 2010 года № 98-ЗРТ «О градостроительной деятельности в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2010, № 12 (II часть); 2011, № 10 (I часть); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7, № 11 (I часть); 2015, № 4; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 41 (часть I), № 85 (часть I); 2018, № 22 (часть I), № 38 (часть I), № 92 (часть I); 2019, № 49 (часть I); 2020, № 1 (часть I), № 4 (часть I), № 26 (часть I), № 87 (часть I); 2021, № 29 (часть I), № 77 (часть I), № 93 (часть I); 2022, № 3 (часть I), № 17 (часть I), № 49 (часть I), № 77 (часть I); 2023, № 11 (часть I) следующие изменения:

1) в части 2 статьи $2^1$:

а) пункт 8 изложить в следующей редакции:

«8) принятие решения о создании, ведении и эксплуатации государственной информационной системы обеспечения градостроительной деятельности Республики Татарстан, в том числе с функциями автоматизированной информационно-аналитической поддержки осуществления полномочий в области градостроительной деятельности;»;

б) дополнить пунктом $10^{10}$ следующего содержания:

«$10^{10}$) определение в соответствии с частью 2 статьи $40^1$ Градостроительного кодекса Российской Федерации объектов капитального строительства, в отношении которых не требуется согласование архитектурно-градостроительного облика;»;

2) в части 6 статьи 5 слова «информационной системе территориального планирования» заменить словами «федеральной государственной информационной системе территориального планирования (далее также – информационная система территориального планирования)», после слов «системы территориального планирования» дополнить словами «(далее – официальный сайт в сети Интернет)»;

3) часть $4^1$ статьи 9 дополнить предложениями следующего содержания: «Органы местного самоуправления поселения, городского округа также вправе подготовить текстовое описание местоположения границ населенных пунктов. Формы графического и текстового описания местоположения границ населенных пунктов, требования к точности определения координат характерных точек границ населенных пунктов, формату электронного документа, содержащего указанные сведения, устанавливаются в соответствии с частью $5^1$ статьи 23 Градостроительного кодекса Российской Федерации.»;

4) в части 8 статьи 10 слова «три месяца» заменить словами «один месяц», слова «, а в случаях, предусмотренных частями $7^1$ и $7^2$ статьи 25 Градостроительного кодекса Российской Федерации, не менее чем за один месяц до его утверждения» исключить;

5) дополнить статьей $10^1$ следующего содержания:

«Статья $10^1$. **Подготовка и утверждение единого документа территориального планирования и градостроительного зонирования поселения, городского округа**

1. Единым документом территориального планирования и градостроительного зонирования поселения, городского округа (далее также – единый документ) признается соответственно генеральный план поселения, генеральный план городского округа, в том числе подготовленные применительно к отдельным населенным пунктам, входящим в состав поселения, городского округа, частям населенного пункта, которые наряду с положением о территориальном планировании и картами, подлежащими включению в генеральный план в соответствии со статьей 23 Градостроительного кодекса Российской Федерации и статьей 9 настоящего Закона, содержат карты градостроительного зонирования, градостроительные регламенты в отношении земельных участков и объектов капитального строительства, порядок применения карт градостроительного зонирования и градостроительных регламентов и внесения в них изменений, включающий в себя положения, предусмотренные частью 3 статьи 30 Градостроительного кодекса Российской Федерации.

2. Обязательным приложением к единому документу являются сведения о границах населенных пунктов (в том числе границах образуемых населенных пунктов), входящих в состав поселения или городского округа, подготавливаемые в соответствии с частью $4^1$ статьи 9 настоящего Закона, и сведения о границах территориальных зон, подготавливаемые в соответствии с частью $6^1$ статьи 30 Градостроительного кодекса Российской Федерации.

3. Решение о подготовке единого документа, решение о подготовке изменений в единый документ принимаются Кабинетом Министров Республики Татарстан. Нормативным правовым актом Кабинета Министров Республики Татарстан может быть предусмотрено, что решение о подготовке единого документа, решение о

подготовке изменений в единый документ принимаются главой местной администрации поселения, городского округа. Одновременно с принятием решения о подготовке проекта единого документа утверждаются состав и порядок деятельности комиссии по подготовке проекта единого документа, которая может выступать организатором общественных обсуждений или публичных слушаний по проекту единого документа, изменений в единый документ при их проведении в соответствии со статьями $5^1$ и 28 Градостроительного кодекса Российской Федерации.

4. Подготовка и утверждение единого документа осуществляются в соответствии с частью 4 статьи $28^1$ Градостроительного кодекса Российской Федерации. Подготовка единого документа обеспечивается местной администрацией. Единый документ, изменения в единый документ утверждаются представительным органом местного самоуправления поселения, городского округа.»;

6) в пункте 1 части 4 статьи 17 слова «, межселенной территории муниципального района» исключить;

7) дополнить статьей $18^1$ следующего содержания:

«Статья $18^1$. **Государственная информационная система обеспечения градостроительной деятельности Республики Татарстан**

1. Государственная информационная система обеспечения градостроительной деятельности Республики Татарстан – создаваемая и эксплуатируемая на основании решения Кабинета Министров Республики Татарстан и в соответствии с требованиями Градостроительного кодекса Российской Федерации информационная система, содержащая сведения, документы, материалы о развитии территорий, об их застройке, о существующих и планируемых к размещению объектах капитального строительства и иные необходимые для осуществления градостроительной деятельности сведения.

2. Кабинетом Министров Республики Татарстан может быть принято решение о создании и ведении государственной информационной системы обеспечения градостроительной деятельности Республики Татарстан с функциями автоматизированной информационно-аналитической поддержки осуществления полномочий в области градостроительной деятельности, позволяющей в том числе осуществлять подготовку, согласование, утверждение документов, указанных в части $7^1$ статьи 56 Градостроительного кодекса Российской Федерации.

3. Создание, развитие и эксплуатация государственной информационной системы обеспечения градостроительной деятельности Республики Татарстан, в том числе с функциями автоматизированной информационно-аналитической поддержки осуществления полномочий в области градостроительной деятельности, обеспечиваются уполномоченным Кабинетом Министров Республики Татарстан органом исполнительной власти Республики Татарстан или подведомственным ему

государственным бюджетным учреждением, которые являются операторами такой государственной информационной системы.

4. Ведение государственной информационной системы обеспечения градостроительной деятельности Республики Татарстан, в том числе с функциями автоматизированной информационно-аналитической поддержки осуществления полномочий в области градостроительной деятельности, осуществляется уполномоченным Кабинетом Министров Республики Татарстан органом исполнительной власти Республики Татарстан (подведомственным ему государственным бюджетным учреждением), органами местного самоуправления муниципальных районов и городских округов в пределах компетенции указанных органов в соответствии с частью $1^1$ статьи 57 Градостроительного кодекса Российской Федерации.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан ____________ Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
06 апреля 2023 года
№ 28-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $2^1$ статьяның 2 өлешендә:

а) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасын, шул исәптән шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруның автоматлаштырылган мәгълүмати-аналитик ярдәм күрсәтү функцияләре белән, булдыру, алып бару һәм аннан файдалану турында карар кабул итү;»;

б) түбәндәге эчтәлекле $10^{10}$ пункт өстәргә:

«$10^{10}$) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $40^1$ статьясындагы 2 өлеше нигезендә аларга карата архитектура, шәһәр төзелеше йөзен килештерү таләп ителмәгән капиталь төзелеш объектларын билгеләү;»;

2) 5 статьяның 6 өлешендә «рәсми сайттан» сүзләреннән соң «(алга таба – Интернет челтәрендәге рәсми сайт)» сүзләрен өстәргә, «территориаль планлаштыруның мәгълүмат системасындагы» сүзләрен «территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасындагы (алга таба

шулай ук – территориаль планлаштыруның мәгълүмат системасы)» сүзләренә алмаштырырга;

3) 9 статьяның $4^1$ өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: «Җирлекнең, шәһәр округының җирле үзидарә органнары шулай ук торак пунктлар чикләре урнашкан урынның текст рәвешендәге тасвирламасын әзерләргә хокуклы. Торак пунктлар чикләре урнашкан урынның график тасвирламасы һәм текст рәвешендәге тасвирламасы рәвешләре, торак пунктлар чикләренә хас булган нокталарның координатларын билгеләү төгәллегенә, әлеге белешмәләр кергән электрон документның форматына таләпләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23 статьясындагы $5^1$ өлеше нигезендә билгеләнә.»;

4) 10 статьяның 8 өлешендә «өч айдан» сүзләрен «бер айдан» сүзләренә алмаштырырга, «, ә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 25 статьясындагы $7^1$ һәм $7^2$ өлешләрендә каралган очракларда аны расларга кимендә бер айдан да соңга калмыйча» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) түбәндәге эчтәлекле $10^1$ статья өстәргә:

«$10^1$ статья. **Җирлекне, шәһәр округын территориаль планлаштыруның һәм аларның шәһәр төзелешен зоналаштыруның бердәм документын әзерләү һәм раслау**

1. Җирлекне, шәһәр округын территориаль планлаштыруның һәм аларның шәһәр төзелешен зоналаштыруның бердәм документы (алга таба шулай ук – бердәм документ) булып тиешенчә җирлекнең генераль планы, шәһәр округының генераль планы, шул исәптән җирлек, шәһәр округы составына керә торган аерым торак пунктларга, торак пункт өлешләренә карата әзерләнгәннәре дә, таныла, аларга территориаль планлаштыру турындагы нигезләмә һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23 статьясы һәм әлеге Законның 9 статьясы нигезендә генераль планга кертелергә тиешле карталар белән бергә шәһәр төзелешен зоналаштыру карталары, җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына карата шәһәр төзелеше регламентлары, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 30 статьясындагы 3 өлешендә каралган нигезләмәләрне үз эченә алган шәһәр төзелешен зоналаштыру карталарын, шәһәр төзелеше регламентларын куллану һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе дә керә.

2. Җирлек яисә шәһәр округы составына керүче торак пунктлар чикләре (шул исәптән төзелә торган торак пунктлар чикләре) турында әлеге Законның 9 статьясындагы $4^1$ өлеше нигезендә әзерләнә торган белешмәләр һәм территориаль зоналар чикләре хакында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 30 статьясындагы $6^1$ өлеше нигезендә әзерләнә торган белешмәләр бердәм документка мәҗбүри кушымта булып тора.

3. Бердәм документны әзерләү турында карар, бердәм документка үзгәрешләр әзерләү хакында карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актында бердәм документны әзерләү турында карар, бердәм документка үзгәрешләр

әзерләү хакында карар җирлекнең, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы тарафыннан кабул ителә дип каралырга мөмкин. Бердәм документ проектын әзерләү турында карар кабул итү белән бер үк вакытта бердәм документ проектын әзерләү комиссиясе составы һәм аның эшчәнлек тәртибе раслана, комиссия, бердәм документ, бердәм документка үзгәрешләр проекты буенча җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $5^{1}$ һәм 28 статьялары нигезендә үткәрелгәндә, аларны оештыручы булырга мөмкин.

4. Бердәм документны әзерләү һәм раслау Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $28^{1}$ статьясындагы 4 өлеше нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм документны әзерләү җирле администрация тарафыннан башкарыла. Бердәм документ, бердәм документка үзгәрешләр җирлекнең, шәһәр округының җирле үзидарәсе вәкиллекле органы тарафыннан раслана.»;

6) 17 статьяның 4 өлешендәге 1 пунктында «, муниципаль районның авылара территориясенең» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) түбәндәге эчтәлекле $18^{1}$ статья өстәргә:

«$18^{1}$ статья. **Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасы**

1. Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы таләпләре нигезендә булдырыла һәм файдаланыла торган мәгълүмат системасы, аңа территорияләрне үстерү, аларда төзелеш алып бару турындагы, гамәлдәге һәм урнаштыру планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектлары хакындагы белешмәләр, документлар, материаллар һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен башка кирәкле белешмәләр керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруның автоматлаштырылган мәгълүмати-аналитик ярдәм күрсәтү функцияләре булган, шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 56 статьясындагы $7^{1}$ өлешендә күрсәтелгән документларны әзерләү, килештерү, раслау мөмкинлеген бирә торган, Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасын булдыру һәм алып бару турында карар кабул итәргә мөмкин.

3. Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасын, шул исәптән шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруның автоматлаштырылган мәгълүмати-аналитик ярдәм күрсәтү функцияләре белән, булдыру, үстерү һәм аннан файдалану мондый дәүләт мәгълүмат системасының операторлары булган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә аның ведомство буйсынуындагы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан башкарыла.

4. Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасын, шул исәптән шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруның автоматлаштырылган мәгълүмати-аналитик ярдәм күрсәтү функцияләре белән, алып бару Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы (аның ведомство буйсынуындагы дәүләт бюджет учреждениесе), муниципаль районнар һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнары тарафыннан үз компетенциясе чикләрендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 57 статьясындагы $1^1$ өлеше нигезендә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 06 апрель
№ 28-ТРЗ